ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.12,
с.Старый Каразерик, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 12 йорт,
Иске Каразирек авылы, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1 26 гыйнвар 2024 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Җирле референдум турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Яжа Каразирек авылында узган үзара салым җыелышының 1 санлы,

2023 елның 16 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Иске Каразирек авылында узган үзара салым җыелышының 2 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р Б И Р Ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: Э.М.Минниярова

Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның 26 гыйнварындагы
1 санлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган тормыш иптәшләре, хәрби хезмәттә булучылардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 25 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 26 гыйнварындагы 1 санлы карарына 2 кушымта

Иске Каразирек авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________________
Адресы: __________________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта______________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә __________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү:

Җитәкче ____________________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Иске Каразирек авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында № __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________________
Адресы: __________________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*